**Исполнительный комитет Поповского сельского поселения Заинского муниципального района Республика Татарстан**

Ул. Центральная, д. 4
с. Поповка, Заинский район, 423503

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Попвка авыл җирлеге башкарма комитеты**

Узәк урамы, 4 нче йорт,
Поповка авылы, Зәй районы, 423503

Телефон, факс 6-27-30, Электронный адрес: Aslob.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 30** **10.12.2019**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында 2019 нчы елның 14 май аенда №18 «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында»**

«Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законы, Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге администрациясе тарафыннан расланган нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 14 май аенда 18 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) көчемсез милек белән идарә итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен раслау;»;

1.3. 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрергә;».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.А.Амерханов